СОВЕТ НОВОЗАРЕЧЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА ЗАРЕЧЕНСК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.06.2020 нчы ел Яңа Зареченск авылы № 149

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яна Зареченск авыл җирлеге Советының дүртенче чакырылыш депутатларын сайлауларны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 3,7 пунктлары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясының 1 өлеше, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Яна Зареченск авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14статьясы нигезендә Яна Зареченск авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Яна Зареченск авыл җирлеге Советының дүртенче чакырылыш депутатларын сайлауларны 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә

2. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, «Хезмәткә дан» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Баулы муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге bavly.tatarstan.ru адресы буенча рәсми сайтының «Яна Зареченск авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

Яңа Зареченск авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе С.Н. Багижева